# ГОМЕР УЗА

*И.МӘҖИТОВ көе*
*Д.ГЫЙСМЕТДИНОВ шигыре*

Гомер уза аккан сулар кебек,
Йөрәкләрдә кала ярасы.
Кемнәр әйтер, кемнәр санап бирер
Тагын күпме калды барасы?

Сөенәм мин кайчак иртәләрен,
Шөкерана кылам язмышка.
Ә кичләрен, янә утлар сүнгәч,
Чумасың шул кайгы - сагышка.

Яшәү, үлем - бары тик бер сукмак.
Нигә башка сукмак юк икән?
Адаштым, дип кире кайтыр идем,
Яшьлегемә кайсы юл илтә?!

Гомер уза искән җилләр кебек,
Йөрәкләрдә кала үкенеч.
Әҗәллərдән дару булмас инде,
Ходай яшәр өчен бирсен көч.